**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№12414**
**22.12.2023**

Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Законы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.22 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының үз компетенциясе чикләрендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген 1 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларының җаваплылык зоналары картасын 2 нче кушымтада каралганча расларга.

Үз көчен югалткан дип таныргa:

1) Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 19 маендагы 2314 номерлы Карары;

2) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 19 маендагы 2314 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 10 мартындагы 1218 номерлы Карары;

3) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 19 маендагы 2314 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 3 октябренедәге 5188 номерлы Карары;

4) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 19 маендагы 2314 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 3 февралендәге 587 номерлы Карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы Л.И. Әхмәтҗановка, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы Э.Р. Фәттаховка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка, Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе башлыгы А.З. Хамматовка, Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы А.Н. Лашинга, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга, Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе башлыгы М.Х. Миннегалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 22 декабрендәге
12414 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитетының үз компетенциясе чикләрендә
Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының
2.1, 2.4 - 2.7, 2.12, 2.13, 2.17, 2.19 - 2.21, 3.2 – 3.6, 3.8, 3.10, 3.11, 3.14 - 3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 статьяларында күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары
исемлеге

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты районнар хакимиятенең Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1, 2.6, 2.7, 2.13, 2.17, 2.19 - 2.21 статьяларында, 3.2 статьясының 3 һәм 4 өлешләрендә, 3.3, 3.4, 3.6 статьяларында күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары:

- район хакимияте Башлыгы;
- территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлеге башлыгы;
- халык белән эшләү бүлекчәсе мөдире;
- территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлегенең баш белгече;
- территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлегенең әйдәүче белгече.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсенең Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.4, 2.5, 2.17, 2.19 - 2.21 статьяларында, 3.2 статьясының 1 һәм 2 өлешләрендә, 3.5, 3.8, 3.10, 3.11, 3.14, 3.15, 3.16, 3.17, 5.1, 5.2, 5.6 статьяларында күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары:

- идарә башлыгы;
- Автозавод районының җәмәгать тәртибен саклау бүлеге башлыгы;
- Үзәк районының җәмәгать тәртибен саклау бүлеге башлыгы;
- Комсомол районының җәмәгать тәртибен саклау бүлеге башлыгы;
- Автозавод районы җәмәгать тәртибен саклау бүлегенең әйдәүче белгече (торак секторда хокук бозуларны профилактикалау һәм индивидуаль профилактик йогынты чараларын куллану буенча инспектор);
- Үзәк районы җәмәгать тәртибен саклау бүлегенең әйдәүче белгече (торак секторда хокук бозуларны профилактикалау һәм индивидуаль профилактик йогынты чараларын куллану буенча инспектор);
- Комсомол районы җәмәгать тәртибен саклау бүлегенең әйдәүче белгече (торак секторда хокук бозуларны профилактикалау һәм индивидуаль профилактик йогынты чараларын куллану буенча инспектор);
- Автозавод районы җәмәгать тәртибен саклау бүлегенең әйдәүче белгече (гаиләдәге уңышсызлыкларны һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча инспектор);
- Үзәк районы җәмәгать тәртибен саклау бүлегенең әйдәүче белгече (гаиләдәге уңышсызлыкларны һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча инспектор);

- Комсомол районы җәмәгать тәртибен саклау бүлегенең әйдәүче белгече (гаиләдәге уңышсызлыкларны һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча инспектор).

3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 4.4 статьясында күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары:

- идарә башлыгы;
- идарә башлыгы урынбасары;
- исәпкә алу һәм мөлкәт белән идарә итү бүлеге башлыгы;
- исәпкә алу һәм мөлкәт белән идарә итү бүлегенең баш белгече.

4. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты административ-техник инспекция идарәсенең Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1, 2.4 - 2.7, 2.17, 2.19 - 2.21, 3.2, 3.3 - 3.6, 3.8, 3.10, 3.16, 3.17 статьяларында күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары:


- идарә башлыгы;
- идарәнең баш белгече;
- идарәнең әйдәүче белгече;
- идарәнең 1 категорияле белгече;
- җирдән файдалануны һәм яшел утыртмалар сакланышын контрольдә тоту бүлеге башлыгы;
- җирдән файдалануны һәм яшел утыртмалар сакланышын контрольдә тоту бүлегенең баш белгече;
- җирдән файдалануны һәм яшел утыртмалар сакланышын контрольдә тоту бүлегенең әйдәүче белгече.

5. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.12 статьясында күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары:

- идарә башлыгы;
- торакны үстерү бүлеге башлыгы.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2023 елның 22 декабрендәге
12414 номерлы карарына
2 нче кушымта




Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева